Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАРЫ

15 ноябрь 2022 ел №17

Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитетының 2013 елның 9 сентябрендәге 3 номерлы «Террорчылыкны һәм экстремизмны, наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру, шулай ук аларның чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерү (яисә) ликвидацияләү турында»гы карарын гамәлдән чыгару хакында

Хокукый мониторинг тәртибендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2022 елның 27 октябрендәге 02-08-02/373-2022 номерлы протестын карап,

Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитетының 2013 елның 9 сентябрендәге 3 номерлы «Террорчылыкны һәм экстремизмны, наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру, шулай ук аларның чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) ликвидацияләү турында»гы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Бишмунча авылы, Совет урамы, 57а йорты, Кама-Елга авылы, Кама-Елга урамы, 26 а йорт, Ак-Чишмә авылы, Ак-Чишмә урамы, 1 йорт, Бакчасарай авылы, Җиләкле урамы, 1 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Бишмунча авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.Г.Фазлиев